Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Югары Чаллы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2024 елның 15 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 15 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Югары Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыны, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2025 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
– җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);
– Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 460 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 243 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 226 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 17 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Югары Чаллы торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Югары Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2025 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

– җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);

– Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына һәм Кызыл Чапчак авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
р.07-5881/27
Совет Краснокадкинского сельского поселения
Кызыл Чапчак авыл җирлеге советы
ИНН 1630003130